# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге Мияш торак пунктында
2024 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**27 ноябрь 2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Мияш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Мияш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

- Мияш торак пунктында һәлак булган сугышчыларга обелиск төзү (обелискны сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Мияш торак пунктында су күтәрү манарасы скважинасы өчен насос сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Тауасты Байлар авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://menselinsk.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы: ______________________ З. С.Гәрәева
(имза)